ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 г. Агрыз № 16

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан «Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү. Мультифаза насослар мәйданы» объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында**

«Теплогазпроект» ҖЧҖ үтенечнамәсен һәм аңа кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан «Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү. Мультифаза насослар мәйданы» объекты буенча ПАО «Татнефть» әзерләгән территорияне планировкалау проектын (планлаштыру проекты составында ызанлау проекты) карап, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, к а р а р и т ә м:

1. ПАО «Татнефть» әзерләгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан «Контузлы нефть ятмасын төзекләндерү. Мультифаза насослар мәйданы» объекты буенча территорияне планировкалау проектын (алга таба – проект) иҗтимагый фикер алышуларга чыгарырга.
2. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә (адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13 йорт, 16 каб., төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге, электрон почта адресы: agrge-stroi@rambler.ru).
3. Билгеләргә:

- проект буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру срогы - 17.03.2022 - 15.04.2022;

- тикшерелә торган проект буенча экспозиция уздыру урыны - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы (адресы: 22214, Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Азево ав., Новая ур., 12);

- фикер алышына торган проект буенча экспозиция ачу датасы - 17.03.2022 ел (8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);

- фикер алыша торган проект буенча экспозиция үткәрү срогы - 17.03.2022 - 15.04.2022 (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр: дүшәмбе-җомга);

- проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү срогы - 15.04.2022 ел;

- проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү урыны: 22214, Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Азево ав., Новая ур., 12 й.

- проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр идентификация узган затлардан эш көннәрендә: дүшәмбе-җомга язмача рәвештә проект экспозициясенә керүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә язу юлы белән кабул ителә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларының башлануы турында хәбәр итү, проект һәм мәгълүмат материаллары «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://agryz.tatarstan.ru) составында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегендә махсус бирелгән мәгълүмат стендына элеп кую юлы белән урнаштырыла дип билгеләргә.
5. Проектның иҗтимагый фикер алышулары йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе һәм иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.
6. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгару срогы - 18.04.2022 ел.
7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегендә махсус бирелгән мәгълүмат стендына элү юлы белән бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасары И.И. Ямалиевка йөкләргә.

Общий отдел
Гомуми бүлек

**А.Р. ВӘЛИЕВ**